КЕМ КҮБРӘК?
КФУ студенты татар телендә тиз укырга өйрәтә

> 3

ИНТЕРНЕТСЫЗ КӨН
«Дөнья пәрәвезе»ннән башка яши алабызмы?

> 4



АЛТЫ АЛКА
«Ак барс» бу сезондагы иң зур җиңүен яулады

> 4

УНИКЕ АДЫМ
Кариев театрында – наркотикларга бәйлелеккә каршы көрәш кыйссасы

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 14 (28981) | Сишәмбе | 31 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИСӘП ВӘ ХИСАП
АВЫЛЛАРДА ХАЛЫК ҖЫЕННАРЫ УЗА

Узган елга нәтиҗә ясап, яңа максатлар билгеләр чак. Авыл һәм район җирлекләрендә узган җыеннарда җитәкчеләр, авыл советлары хисап тотса, халык борчыган мәсьәләләрен әйтеп калырга тырыша.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мөслим районының Метрәй авылында район башлыгы Альберт Хуҗин катнашындагы халык җыены берничә көн элек кенә узган. Авыл советы башлыгы Илдус Шәмгунов әйтүенчә, җирлеккә биш авыл (Ольгино, Салауз-Мухан, Метрәй, Иске Чакмак һәм Үрнәк) керә. Аларда барлыгы 1052 кеше яши.

– Мин әлеге вазыйфага узган елның июнендә генә керештем. Халыкның мөрәҗәгатьләрен игътибарсыз калдырмыйча, ярдәм итәргә тырыштым. Җирлектә ниндидер зур проблемалар бар, дип әйтә алмыйм. Ә инде көндәлек, вактөяк мәшәкатьләрне булдыра алганча хәл итеп барырга тырыштык, – диде ул.

Узган ел башкарылган зур эшләрдән Ольгино, Салауз-Мухан авыллары зиратларын коймалар белән әйләндереп алуын әйтте. Халыкның күптәннән әйтеп килгән үтенече булган ул. Моннан тыш, электр чыбыкларына, газ торбаларына комачаулык иткән агачларны кискәннәр. Билгеле ки, әлеге зур эшләр белән бергә көнкүрештә килеп чыккан көтелмәгән мәшәкатьләрне дә хәл итәргә туры килгән. Әйтик, насосларны, торбаларны алыштырганнар, юлларны төзекләндергәннәр.

Эшләр быелга да җитәрлек. Шул ук агачларны кисү, урам утларын алыштыру, су каланчасы янында җылытылган корылма эшләп куймакчылар метрәйлеләр. Моннан тыш, юлларны төзекләндерергә, паркларны да карарга уйлыйлар. Халык клубта уйнар өчен бильярд өстәле дә сорый икән. Быел анысын да кайтарып куймакчылар.

– Метрәй авылына кергәндә халык асфальт юл сорый. Чөнки ком-таш кушылмасы түшәлгән юл җәйге коры көннәрдә бик тузанлы, комлы була. Кызганыч, моны башкарып чыгу безнең көчтән генә килә торган эш түгел. Шуңа күрә төрле юлларын карыйбыз. Гозеребезне депутатларга җиткердек, – диде Илдус Шәмгунов.

Авыл халкы үзара салым акчасының файдасын күп күрә, дип белгеләп узды җирлек башлыгы. Моңа кадәр ерып чыга алмаган күп кенә эшләр нәкъ менә шушы акча хисабына башкарылган. Быел да исә халык, узган елгы шикелле үк, уртак казнага 1 мең (Метрәй, Салауз-Мухан) һәм 750 сумнан (Ольгино, Иске Чакмак) акча җыярга килешкән.

Апас районының Каратун җирлегендә җыен район башлыгы Айрат Җиһаншин, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, социаль яклау бүлеге вәкилләре, участок полициясе катнашында узган. Узган атнада халык аларга әйтәсе килгән гозерләрен, тәкъдимнәрен җиткергән.

– Узган ел эшләгән иң зур эшебез 2 млн сумга чүплек контейнеры мәйданын ясап кую булды. Безнең җирлектә чүпне капчыклар белән Морзалар авылыннан гына җыялар. Моңа кадәр башны иң нык авырттырган мәсьәлә контейнерлар янын чиста-пөхтә итеп тоту иде. Чөнки кешеләр савыт тирәләренә күләмле көнкүреш калдыклары китереп ташлыйлар иде. Бу контейнерларны түбә астына кертеп, коймалап алып, матурлап җибәргәч, карап туймаслык булып үзгәрде. Халыкка да, гел шул чисталыкны саклыйк, дип әйтеп торам, – дип сөйләде җирлек башлыгы Радик Исмәгыйлев.

Узган ел өлкәннәрне сөендерсәләр, быел кечкенәләрнең күңелләрен күрмәкчеләр: ике авылда балаларга уен мәйданчыклары ясап куймакчы булалар. Аларын узган ел үзара салым акчасына алган булганнар. Моннан тыш, юлларны да рәтлиселәре бар икән.

– Халык Морзалар авылында юлдагы ясалма түмгәк («лежачий полицейский») сорый. Тик минем аны башкарып чыгар өчен мөмкинлегем юк. Күрше Ябалакка бара торган юл шушы авыл аша уза, шуңа күрә кызу йөргән машиналар халыкка куркыныч тудыра. Моннан тыш, җыенга килгән кешеләр терлек асрауга кагылышлы сорауларын да бирде. Пособиеләр, ярдәм чаралары белән кызыксынды, – диде җирлек башлыгы.

Узган ел Минзәлә районының Хуҗамәт авыл җирлегендә зур эшләрдән су скважинасы казыганнар, насослар алганнар, зиратларны тәртипкә салганнар. Җирлек башлыгы әйтүенчә, җыенда кешеләрдән агачлар утыртырга тәкъдим булган. Анысын быел башкарып чыкмакчы булалар. Моннан тыш, агымдагы елда скважинаны төзекләндерергә, зиратка кирәк-яраклар алырга һәм балалар мәйданчыклары ясарга планлаштыралар.

– Безнең җирлеккә биш авыл – Хуҗамәт, Усай, Балтай, Бакчасарай һәм Яңа Александровка керә. Төп проблемабыз – күпкатлы йортларда канализация мәсьәләсе. Шуңа күрә халыкның күп сораулары шушы тирәдә булды. Җыенга идарәче компания вәкилләре дә чакырулы иде. Алга таба шушы авырлыкны хәл итү юлларын караячакбыз, – диде Зөһрә Мортазина.

Җайлы сәүдә

Узган елда Татарстан интернет-сәүдәне үстерү буенча Идел буе федераль округында беренче урынга чыккан. Интернет-кибетләрдә республика сәүдәгәрләренең сату әйләнеше ике тапкыр арткан. Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Татарстан Президенты каршындагы вәкаләтле вәкил, Президент ярдәмчесе Фәрит Абделганиев әйтүенчә, мондый сату әйләнеше бездә 50 миллиард сумга җиткән.

Маркетплейсларда сатучылар саны да ике тапкыр диярлек ишәйгән: 2022 елның 1 гыйнварына 23 мең булса, быел 1 гыйнварга аларның саны 45 меңнән артып киткән.

Татарстанда интернет-сәүдәне үстерү программасының җимешләре бу. Инде менә Премьер-министр Алексей Песошин республикада 2023–2025 елларга интернет-сәүдәне үстерүнең яңа программасын раслаган. Ул инфраструктура һәм логистиканы үстерү, товарларны таныту кебек мәсьәләләрне үз эченә ала. Программада Татарстан территориясендә бонд складын булдыру буенча эксперимент үткәрү өчен шартлар тудыру каралган. Ул апрель аеннан башланачак.

Сүз уңаеннан, Татарстан узган елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча Россиянең интернет-сәүдә өлкәсендә иң актив төбәкләре унлыгына кергән. Челтәр аша сатылган товарларның 1,9 проценты республикага туры килгән. Беренче өч урында – Мәскәү, Мәскәү өлкәсе һәм Санкт-Петербург.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >



picjumbo.com

Шаляпин кичләре

Казанда Федор Шаляпин исемендәге XLI Халыкара опера фестивале башланды. Ул 28 февральгә кадәр дәвам итәчәк. Фестивальнең беренче чарасы – Джоаккино Россининың «Сивильский цирюльник» спектакленең премьерасы. Аны Италия режиссеры Джузеппе Морасси сәхнәләштергән. Шунысы кызык: әлеге спектакльдә кайчандыр Федор Шаляпин үзе дә катнашкан була. Гомумән алганда, фестиваль кысасында ун спектакль һәм ике гала-концерт узачак. Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә Россия опера сәнгатенең танылган артистлары белән беррәттән Италия, Белоруссия, Грузия һәм Азәрбайҗаннан килгән кунаклар да чыгыш ясаячак.

Быелгы фестиваль Федор Шаляпинның 150 еллыгына багышланган. Әлеге дата 13 февральдә билгеләп үтелә. Шул җәһәттән Россия Банкы өч мең данә тираж белән әлеге шәхеснең исеме сугылган ике сумлык көмеш тәңкәләр чыгара башлый.

Ай башында суыта

Февраль башында сизелерлек суытачак. Республика Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 1 февральдә көндез –5...–10 градус салкын булачак. Явымтөшем көтелми. Төнлә –12 градуска кадәр суык, аз гына кар көтелә. Пәнҗешәмбе – 2 февральдән суыта. Көндез –5...–10, төнге сәгатьләрдә –10...–15, урыны белән –20 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, җомга, шимбә – 3–4 февральдә Татарстанда болытлы һава саклана. Урыны белән кар. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –2...–7 градус чикләрендә тирбәлсә, төнлә –7...–12, урыны белән 15 градуска кадәр төшәчәк.

Куркыныч газ

Республикада ел башыннан бирле сөрем газыннан агуланучылар саны, узган елның шушы ук чорындагыга караганда 2 тапкыр артып, 25 кешегә җиткән. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 1–29 гыйнвар көннәрендә сөрем газыннан агулануның 12 очрагы теркәлгән. Барлыгы 25 кеше (шул исәптән 11 бала) зыян күргән, икесе һәлак булган. 2022 елның беренче аенда исә 7 шундый очрак булып, 12 кеше (шул исәптән дүрт бала) зыян күргән, ике кешенең гомере өзелгән.

29 гыйнварда Казан, Әлмәт һәм Азнакай районнарында сөрем газыннан агулану очраклары булды. Берсе фаҗига белән тәмамланды. Азнакай районының Актүбә бистәсендә утын белән ягыла торган мунчада ис тиеп, 78 яшьлек ир-ат һәм 63 яшьлек хатын-кызның гомере өзелде. Биш кеше зыян күргән (өчесе – балалар).

Югалту

Тынгысыз йөрәк

Үз эшенең остасы, ышанычлы дус, тынгысыз йөрәк, оста җитәкче. Вакытсыз вафат булган Марат Садыйковны якыннары, дуслары, хезмәттәшләре шулай дип искә ала. Татарстанның сәламәтлек саклау министрына бәйле хатирәләрне яңартканда көчле зат саналган ир-атлар да күз яшен тыеп тора алмады. Аның белән хушлашырга теләүчеләр күп булу сәбәпле, хәтта озату мәрасименең урынын үзгәртергә мәҗбүр булдылар. Исемен исә ул үзе эшләгән хастаханәгә биреп, мәңгеләштерергә тәкъдим итәләр.

Үзе җитди, үзе – үз кеше

Узган якшәмбе иртәсе кайгылы хәбәрдән башланды. Ял көненә каршы төндә 53 яшендә Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков вафат булды. Республиканың сәламәтлек тармагы өчен янып-көеп йөргән министрның йөрәге әнә шулай – һич көтмәгәндә туктаган. Узган җомгада ул 53 яшен тутырган иде. Котлаучылар арасында сәламәтлек теләүчеләр дә күп булгандыр.

Әле ике атна элек кенә министрлыкның узган елгы эш йомгакларына багышланган коллегия утырышында киләчәккә зур максат-бурычлар куйган иде ул. Ни кызганыч, аларны үзенә чынга ашырырга язмаган булган икән.

Быелның февралендә Марат Садыйковның министр вазыйфасына билгеләнүенә биш ел тулган булыр иде. Яшерен-батырын түгел, соңгы бишьеллык республиканың медицина тармагы өчен аеруча катлаулы булды. Коронавирус котырган пандемия чоры аеруча нык сынады.

Ләкин Марат Садыйков житәкчелегендәге медицина тармагы бу сынауны лаеклы рәвештә узды. Республика хастаханәләре тиз арада кирәкле җиһазлар, медицина кирәк-яраклары, дарулар белән тәэмин ителде. Казанда кыска вакыт эчендә өр-яңа инфекция хастаханәсе төзелде.

Ул эшләгән чорда Чаллыда күптән көтелгән онкология диспансеры да ачылды. Казанда балалар онкология үзәге, 7 нче хастаханә базасында тернәкләндерү үзәге, Түбән Камада ашыгыч медицина ярдәме үзәге эшли башлады. Бу әле иң зурлары гына. Республиканың бар почмагында телемедицина технологияләре кулланылу да – Марат Садыйков көче белән ирешелгән уңыш.

Кешелеклеге белән дә истә калды. Хәтерләсәгез, 2021 елның декабрендә юл фаҗигасенә очраган хатын-кызга ярдәм иткән иде ул. Узган елның гыйнварында исә Марат Садыйков Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән Казанга юл тоткан очкычта хәле авырайган хатын-кызга да беренче ярдәм күрсәтте. Аны якыннан белгән кешеләр әйтүенчә, мондый очраклар бик күп булган.

Яшерен-батырын түгел, җитәкче вазыйфасын биләгән кеше турында төрле сүзләр ишетергә туры килә. Әмма Марат Садыйков турында ялгышып кына да начар сүз, хатирә белән уртаклашкан кеше юк. Моңа тагын бер кат инану өчен социаль челтәрләрдә аның үлеме турындагы хәбәрләр астындагы фикерләрне ачып уку да җитә. Алар арасында бер генә тискәре фикер дә тапмассың! Һәркем аңа рәхмәт әйтә, кайгы уртаклаша, министрга бәйле якты хатирәләр белән генә бүлешә. Без – журналистлар хәтерендә дә мәрхүм министр ачык, ярдәмчел, үзен беркайчан да өстен куймавы, иң четерекле сорауларга да тиз арада җавап бирергә тырышуы белән истә калачак. Кирәк урында җитди, кирәк урында, уенын-чынын бергә кушып, үз кеше була белде.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ЗОРИН, Россия Иҗтимагый палатасының Милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү комиссиясе рәисе:

Узган җанисәпне үрнәк дип атау дөрес булмас. Әмма статистика белән эшләүчеләрнең, волонтерларның, студентларның, өлкән буын вәкилләренең катлаулы шартларда башкарган хезмәтен дә сызып ташлау мөмкин түгел. Җанисәпне бөтенләй дә уңышсыз дип атау өчен альтернатив нәтиҗәләрне күрсәтергә, ягъни моны расларга кирәк. Ләкин Россиядә халык турындагы мәгълүмат бу дәрәҗәдә тупланган башка чыганак юк.

(«Миллиард.Татар»дагы әңгәмәсеннән)

ИДЕЛ БУЕ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ – АШЛЫК УҢЫШЫ

Узган ел Идел буе федераль округы төбәкләрендә 36,9 млн тонна бөртекле уңыш җыеп алынган. Бу – соңгы 33 елдагы иң зур күрсәткеч. 2021 ел белән чагыштырганда 2 тапкыр диярлек күбрәк. Илдәге ашлык уңышының 24 проценты Идел буе төбәкләрендә җыеп алына.

Саратов өлкәсе	6,48 млн тонна
Башкортстан	5,55 млн тонна
Татарстан	5,18 млн тонна



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СЕРЛЕ ҺӨҖҮМ

Үткән атнаның шимбәсеннән якшәмбегә каршы төн тагын да зуррак тынычсызлыкта үтте. Газета хәбәрчесенә Иранның хәрби объектларына беспилотник һөҗүмнәре турындагы беренче хәбәрләр таң алдыннан килде. Таң атканда ул инде: «Израиль Азәрбайҗандагы базадан Иранга һөҗүм итте. Ничек уйлыйсың: Иран Азәрбайҗанга каршы сугыш башлармы икән?» – дигән беренче сорауны алды.

Килеп ирешкән хәбәрләр, чынлап та, шомлы иде. Алардан күренгәнчә, бердән, һөҗүм массакүләм характерда, икенчедән, төрле объектлар утка тотылган. Дөрес, рәсми Тәһран бары тик өч беспилотник һөҗүм итте, берсе бәреп төшерелде, икесе тозакка эләкте дигән белдерү ясады. Әмма мәгълүмат кырында Исфаханда (Иранннның атом-төш объектлары шунда урнашкан) һәм Көнчыгыш Азәрбайҗанда (Иран төбәге) куәтле шартлаулар һәм янгыннар, Көнбатыш Азәрбайҗанда 5,9 баллы җир тетрәү, йөзләгән яралы турында сүзләр таралды. Үлүчеләр дә бар, диделәр. Иранның хәрби һәм атом-төш җир асты объектлары урнашкан урындагы җир тетрәү сораулар уята: тектоник плитәләрнең хәрәкәте табигый рәвештә булдымы, әллә куәтле бункер бомбалары белән ясалган һөҗүм нәтиҗәсеме? Җир астында яшерелгән кораллар шартларлык итеп беспилотник һөҗүм итә алмый, куәтле ракета яисә бомбага тотучы очкыч кирәк. Җир асты бункерларын шартлатырлык корал бары тик бер илдә генә бар.

Һөҗүмне Израиль АКШ ярдәме белән оештырды дигән фикер өстенлек алса да, гыйбриләр дә, Вашингтон ягы да эндәшми. Израильнең позициясе һәрвакыт шундый: һөҗүм ясый да җаваплылыкны үз өстенә алмый, кире дә какмый. Аналитиклар баш вата: Иранның җавабы нинди булыр? Тәһран һәрвакытта да Израильне Җир йөзеннән юк итәчәге турында гаугалы белдерүләр ясарга яратса да, моңа кадәр әле бер тапкыр да гыйбриләр дәүләтенә җитди зыян салырлык адым ясаганы юк. Израиль Сүриядәге Иран базаларын даими утка тотып торса да, Иран хәрбиләре бер тапкыр да җавап бирмәде. Әлбәттә, соңгы һөҗүм – илнең эчке төбәкләренә үтеп кереп ясалуы белән моңарчы күзәтелмәгән хәл, әмма Тәһранның үзен берни дә булмаган кебек тотуы өметләндерә: төбәк сугыш уты эчендә калмас, мөгаен.

Шул ук вакытта җавапсыз калдыру тагын да куәтлерәк һөҗүмнәр сериясен китереп чыгарырга ихтимал. Газета хәбәрчесе мәгълүмат кырыннан тапкан версияләр һәм фаразлар бу язмадагы юллар санына караганда күбрәк. Ниндидер кара көчләр Якын Көнчыгышта (Төркияне дә кертеп) зур янгын чыгарырга тели, монысы аңлашыла. Төбәктә зур болганчыклык башланачагын без һәрвакыт әйтеп килдек. Вәләкин безнең күзаллау буенча зур хаос Иран – Израиль конфликты рәвешендә булырга тиеш түгел. Башта Якын Көнчыгышта урнашкан дәүләтләрдә тәхетләр селкенә, аннан соң үзара конфликтлар кыза. Газета хәбәрчесе вазгыятьнең алгоритмын шулайрак күзаллый. Үткән еллардагы һөҗүмнәр төбәккә ут салу функциясен үти алыр иде, бәлки. Нәрсә генә булмасын, Израиль Украинадагы үз инструкторларын (538 хәрби) чакыртып алды, АКШның хәрби йөк самолетлары Израильгә оча дигән хәбәрләр ишетелде. Гыйбри дәүләтендә эчке сәяси хәл бик тотрыксыз, яңа гына сайланган Нетаньяху кабинеты таркалып, җимерелеп бара. Киеренкелек гыйбриләрнең игътибарын эчке проблемалардан читкә юнәлтү максатыннан да оештырылырга мөмкин.

Россиядә

ЙОМГАК ЧУАЛА, ТӨЕННӘР АРТА

Россиядә изоляция һәм санкцияләргә бәйле проблемаларның зур йомгагы төенләнә. «Коммерсантъ» нефтьчеләрнең Россия тимер юллары компаниясенең нефть продуктларын көнчыгышка ташудан бик еш баш тартуыннан зарлануы турында яза. 5 февральдә эмбарго үз көченә кергәч, хәл катлауланыр дип куркалар.

Бик зур нефть эшкәртү заводлары (арада Татарстанның ТАНЕКОсы да бар) тимерьюлчылар белән уртак тел таба алмый. Мәсьәләне Энергетика министрлыгы һәм Монополиягә каршы федераль хезмәт дәрәҗәсенә күтәреп караганнар, әмма хәл ителмәгән. Продукцияне озата алмау җитештерүнең кимүенә китерәчәк, компанияләр шулай дип чаң суга. Илнең көнчыгыш төбәкләре нефть продуктлары кытлыгы кичерә башларга да мөмкин. Сүз экспортка озатыла торган чимал турында бармый. Тимерьюлчылар акланалар, әмма, күрәсең, барлык чимал товарларын көнчыгышка берьюлы боргач, куәтләре җитми.

Банкирларның үз кайгысы: табыш 2015 елдан соң иң түбән дәрәҗәдә. 2021 елда банклар 2,4 триллион сум табыш алган булсалар, 2022 ел нәтиҗәләре 11,8 тапкыр түбәнрәк. Беренче яртыеллыкта 1,5 триллион сумлык зыян да күрелгән әле, вазгыять көзгә таба гына табышлыга әйләнгән.

Халык кулланушы товарлары базарында да хәл сөенечле түгел. Беренче карашка базар 13,6 процентлык үсеш күрсәткән, ягъни саннарга карап, барысы да яхшы дип сөенерлек. Әмма үсеш – инфляция нәтиҗәсе. Реаль куллану тискәре сан күрсәтә: –3,4 процент. Бу 2014–2015 еллар кризисыныкына караганда да начаррак. Ул чакта түбәнәю 1,5 процент кына булган. Түбәнәюнең төп сәбәбе – халыкның реаль керемнәре кимү. Россиялеләр чыгымнарын оптимальләштерә, диләр белгечләр. Оптимальләштерү айдан-айга, кварталдан-кварталга көчлерәк сиздерә. Дүртенче кварталда халык көндәлек кирәк-яракларны гына түгел, азык-төлекне дә кимрәк сатып ала башлаган.

Соңгы айларда сәүдә үзәкләрендә зур янгыннар күзәтелде. Бу иминиятләштерү базарында хәлне кискенләштергән. Янгыннардан иминиятләштерү бәяләре 2023 елда 5–20 процентка кыйммәтләнгән. Иминиятләштерүчеләр янгын сәбәпләрен тикшерүгә дә игътибарлырак һәм таләпчәнрәк була башлаган. Әгәр сәүдә үзәгендә янгынга кадәр кимчелекләр табылган булса, зыянны каплату кыенлашкан.

Бизнеска үткән елда өстәмә салымнар һәм штрафларны да ике тапкыр диярлек күбрәк түләргә туры килгән. Салымнар күбрәк җыелуга карамастан, дәүләт әҗәте 2,2 триллион сумга үскән.

ҺӘР ТӨБЕ КАДЕРЛЕ

Нәтиҗә

Янмасын урман! Татарстан урманчыларына әнә шундый бурыч куелды. Хәер, 2023 елда башкарылачак эшләр моның белән генә бетми. Быел урман чикләрен билгеләү дә, урманчылыклардагы биналарны төзекләндерү дә, урман утырту да, аларны чүпләрдән чистарту да дәвам итәчәк. Кыскасы, агач үскәнне, күктән яңгыр төшкәнне генә көтеп утырасы юк. Бу хакта Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе утырышында сөйләштеләр.

– Татарстанда узган ел 51 питомникта 33 миллион үсенте, Саба селекция- орлыкчылык үзәгендә 12 миллион данә ябык тамырлы кәлшәләр үстерелде. 14 мең килограмм орлык җыеп алынды, – диде утырышта министр Равил Кузюров. – «Экология» илкүләм проекты кысасында күп эшләр башкарылды. 3,6 мең гектар мәйданда урман утыртылды. Максатыбыз – «Урманнарны саклау» федераль проекты ярдәмендә кимегән һәм торгызылган урманнар нисбәтен 100 процентка җиткерү. Бу күрсәткечкә 2024 елда ирешербез дип уйлыйбыз.

Шөкер, 2022 елда Татарстанда урманнарда янгын булмады. Әмма коры үләнгә ут кабуның 352 очрагы теркәлгән. Урманга куркыныч янаган районнар арасында Чистай, Түбән Кама, Әлмәт, Биектау, Алабуга, Лаеш, Зәй, Лениногорск, Мамадыш районнары бар.

– Янгын гына түгел, агачларны авырулар да сыный. Узган ел ефәк күбәләге 64 мең гектар мәйданга зур зыян салды. Әле дә шуның белән көрәшәбез, – диде Равил Кузюров.

Министр урманга бөҗәкләрдән килгән зыян турында гына түгел, аңа кешеләр тарафыннан булган мөнәсәбәт турында да сөйләде. Бер ел эчендә урман инспекторлары 33 мең тапкыр патрульгә чыгып, 73 мәртәбә тикшерү уздырган. кизү ясаган. Урманга 50 миллион сумлык зыян килгәне ачыкланган.

Урманчыларның эшләрен санап бетерерлек түгел. Өмәләр, агач утырту белән беррәттән үсентеләрнең исәбен алу, аларны төрле авырулардан саклау янәшәсендә цифрлаштыру эше дә дәвам итә. Алар урман фондын да барлау белән мәшгуль.

– Республикада урман чикләрен билгеләү эшләре дә дәвам итә. Татарстанда 16 мең 800 җир мәйданына чик куярга кирәк. 11 мең 300 кишәрлек турында милек реестрларында бернинди мәгълүмат юк. Бу юнәлештә эшебезне дәвам итәбез. Тик яткан авыл хуҗалыгы җирләрен урман фондына кертергә кирәк, – диде министр.

Урман тармагында эшләүчеләрнең 36 процентын 40 яшькә кадәрле хезмәткәрләр тәшкил итә. Равил Кузюров Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка яшь кадрларга игътибары өчен рәхмәт әйтте. Вуз тәмамлап, бу эшкә килүче яшь белгечләргә – 300 мең сум, урта һөнәри уку йортында белем алганнарына 150 мең сум түлиләр. Берәр мәртәбә түләнүче әлеге акчаны 10 белгеч алган инде. Акча дигәннән, министр җитәкчеләрдән урманчыларның хезмәт хакларын арттыруны да сорады.

– Без урманга яшьләрне тартырга тиеш. Моның өчен инде кечкенә балалар белән эшлибез. Республикада 114 балалар урманчылыгы эшли. Аларга 1 мең 500 бала йөри. Әлегә барысы да – урман сагында. Шул сабыйларны ничек тә үзебезгә тартасы иде, – ди ул.

Идел буе федераль округы буенча Урман хуҗалыгы департаменты җитәкчесе Александр Орнатский республика урманчыларын башка төбәкләргә үрнәк итеп куйды. Татарстан Премьер-министры урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин исә урман янгыннарын булдырмаган өчен рәхмәт әйтте.

– Урманчылар бик зур хезмәт башкара. 2022 елда тармакта 13 дәүләт хезмәте цифрлашкан. Чикләрне билгеләү дә бик мөһим эш. Моны дәвам итәргә кирәк, – диде ул. – Янгынга каршы сезонга алдан ук ныклап әзерләнергә, барлык кирәк-яракны алырга кирәк. Урманнарны бергәләп саклыйк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АК БЕЛӘН КАРАНЫ БУТАМАСКА!

Чипсы ашап үскән буында Ватан кайгысы бармы? Быел мәктәпләрдә унбишенче мәртәбә парламент дәресләре узачак. «Без – Россия гражданнары» дип аталган дәресләрдә ватанпәрвәрлек темасының урыны түрдән булачак. Тиздән мәктәпләрдә яңа тарих дәресләре дә дөнья күрәчәк. Хокукын белгән замана баласы бурычларын да беләме?

tatarstan.ru

Быел парламент дәресләре Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышлана. Татарстан Дәүләт Советында район һәм шәһәр мәгариф бүлекләре җитәкчеләре, тарих, җәмгыять белеме, хокук укытучылары белән очрашуда парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин әлеге дәресләрне уздыру, яшь буында әхлак, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү турында да сөйләште. Дәресләр 1 февральдән башлана.

– 14 ел эчендә уздырылган парламент дәресләрендә үсеп килүче буында республиканың иҗтимагый-сәяси үсешенә кызыксынуын сизелерлек рәвештә арттыра алдык. Әлеге дәресләрнең укучыларга кызыклы булуына үзем дә мәктәпләргә барган саен инанам, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Фәрит Мөхәммәтшин хәзерге вакытта балаларда һәм яшьләрдә гражданлык-патриотик хис тәрбияләү мәсьәләләренең беренче урынга чыгуын әйтте. Аның фикеренчә, шәхеснең рухи нигезен торгызуда, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүдә гаилә төп рольне уйный. Шулай ук безнең балалар рухи яктан нык булсын өчен, мәктәп һәм укытучылар да бу зур эшнең башында торырга тиеш.

– Гаиләнең әһәмиятен күтәрергә кирәк. Аннан туган илгә, анда яшәүче халыкларга мәхәббәтне мәктәп, техникум, институтта ныгытырга! Яшьләрне Бөек Ватаны сугышы, Хезмәт геройлары үрнәгендә тәрбияләргә кирәк, – диде парламент башлыгы.

Чыгышын тәмамлап, республика укытучыларына хезмәтләре өчен рәхмәтен белдереп: «Чынлыкта сездәге власть Премьер-министрда да юк. Сез үсеп килүче яшь буынның акылын формалаштырасыз. Киләчәк буынның акылы – сезнең кулда. Республикабыз һәм илебезнең, бөтен күпмилләтле халыкның киләчәге – сезнең кулда», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советының татар һәм рус телләрендә законнар текстларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе Римма Ратникова белдергәнчә, патриотизм һәм традицион кыйммәтләрне саклау темасы бүген аеруча актуаль. Аның әйтүенчә, бүген интернет киңлекләрендә ялган мәгълүмат ташкыны агылганда, яшьләрне акны карадан аерырга өйрәтүгә карата ихтыяҗ зур.

Ул Россиянең мәгърифәт министры Сергей Кравцов сүзләрен китереп, бүген Россия мәктәпләренең үз мәгълүмат «фронт»ы җәелүен әйтте. «Педагогларга ялган һәм коткыларны фаш итәргә, безнең илгә һәм балаларыбызга карата агрессия белән көрәшергә, аларны ялганнан сакларга туры килә», – диде Римма Ратникова.

Мәктәпләрдә әлеге дәресләргә ничек әзерләнәләр? Балалар хокукларын гына түгел, бурычларны да беләләрме?

Әлмәттә әле узган көздә генә ачылган «Адымнар» мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Гөлнара Гатауллина да яңа мәктәптә беренче парламент дәресен бирәчәк. Ул шул ук вакытта Сөләй авыл мәктәбенә дә барып укыта икән.

– Без XXI гасырда яшибез. Балалар исә программа буенча XX–XXI гасырны нибары 10 нчы сыйныфларда гына өйрәнә. Кечкенә сыйныфларда Бөек Ватан сугышы, милләтләр арасында мөнәсәбәтләр турында өстәмә дәресләр кирәк. Шуңа күрә парламент дәресләренең файдасы зур, – ди Гөлнара Гатауллина. – Әгәр укытучы дәресне кызыклы итеп, аны бүгенгә бәйләп оештыра икән, әлбәттә, балаларга кызык.

Укытучы бүгенге балаларның, минем хакым бар, дип сөйләшергә яратуын да әйтте. «Безнең бурыч – хокукларны гына түгел, бурычларны да аңлату», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Яңалык

Сөткә тамга сугалар

Алга таба кибет киштәсендәге сөт-эремчекнең куллану вакытын карап, төпченеп өйрәнеп торасы булмаячак. Быелдан азык-төлек кибетләрендә яңалык гамәлгә керде. Ягъни куллану вакыты чыккан сөт ризыклары, сатып алучы кәрзиненә эләксә дә, кассадан узмаячак. Дөрес, тәҗрибә рәвешендәге бу эшкә, иң беренче чиратта, кибетләр үзләре ризалык бирергә тиеш.

Илнең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы ваклап сатудан куллану вакыты чыккан продукцияне йолып алуга бәйле яңалыкны узган ел ахырында хәбәр итте. Эш шунда ки, белгечләр кибет киштәсендәге товарларга өстәмә тамга сукмакчы. Азык-төлек яки көнкүреш кирәк-яракларының куллану вакыты турындагы мәгълүмат әнә шул билгедә «яшеренәчәк» тә инде. «Кибетләрдә куллану вакыты чыккан товар сату очраклары бик еш күзәтелмәсә дә, моңа каршы даими көрәшергә туры килә», – дигәннәр министрлыкта. Нигездә, бу сатучыларның эшенә салкын каравы, киштәләрне вакытында тикшермәве аркасында килеп чыга, дип тә өстәгәннәр. Озын сүзнең кыскасы: куллану вакыты чыккан товар касса аша узмаячак. Әлегә тәҗрибә рәвешендәге эштә катнашу ирекле. Яңалыкның ни дәрәҗәдә нәтиҗәле икәнен сынап карамакчылар.

Кибет хуҗаларыннан җавап та озак көттермәде. Киң таралган азык-төлек кибетләренең берсе тамганы иң элек сөт ризыкларында тикшереп карарга тәкъдим итте. Кызыл кием кигән сатучылар каймак-майларга махсус билгене бу айда ук суга башлаган.

– Гадәттә, куллану вакыты чыгарга бер-ике көн калган товарларны очсызрак бәядән сатып җибәрергә тырышабыз, – ди башкаладагы супермаркетларның берсендә директор урынбасары булып эшләүче Алия Минһаҗева. – Халык ташламалы әйберләрне бик теләп сатып ала. Элек мондый товарлар өчен кибеттә аерым урыннар да бар иде. Хәзер болай эшләргә ярамый. Шуңа күрә ташламалы азык-төлек сатып алырга иярләшкән әби-бабайлар кибет буйлап аптырап йөри. Ә кибет киштәсендә куллану вакыты чыккан азык-төлек тапсалар, товарны бушлай биреп җибәрәбез. Нишлисең, безнең гаеп бит. Кефир, йогыртларның тәме куллану вакыты чыккач та тиз генә бозылмый әле.

Илнең Авыл хуҗалыгы министрлыгында сатудан калган сөт ризыкларын урнаштыру җаен да тапканнар әнә. Алар куллану вакыты чыккан сөт-майларны фермер хуҗалыкларына озатырга тәкъдим иткән. Малларга азык әзерләү өчен менә дигән чимал, янәсе. Дөрес, бу яңалык түгел икән инде. X5 Group челтәренә керүче «Пятерочка», «Перекресток» кибетләрендә, мәсәлән, күптән шулай эшлиләр. «Кулану вакыты чыккан сөт ризыкларын, яшелчә, җиләк-җимеш, ипине очсыз бәядән сыер асраучы шәхси эшмәкәргә сатабыз. Бер капчык ипи, мәсәлән, 100 сум тирәсе тора», – дип аңлаттылар шундый кибетләрнең берсендә «ВТ» хәбәрчесенә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Физик культура һәм спорт өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Ибраһимов** Сәгыйт Габдерәүф улы **Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлеге советы рәисе **Камалетдинов** Радик Раил улы **Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары **Галимуллин** Илшат Әхәт улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Бөтендөнья татар конгрессының республика иҗтимагый фонды әйдәүче референты **Зәйнетдинова** Әлфия Рәкыйп кызы; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомбыт авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры **Зиннәтуллина** Резеда Хәйретдин кызы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе **Хәмидуллин** Раил Хәмбәл улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең ут куючы рәссамы **Ишмәтов** Шамил Ибраһим улы, «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Миңнуллина** Ләлә Рафаил кызы; республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иҗтимагый советы әгъзасы **Мәннапов** Ромель Зөфәр улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасының «Кулланучылар хокукларын яклау» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Нигъмәтуллина** Юлия Рөстәм кызы; яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә һәм республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Әфганстан ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы Югары Ослан бүлекчәсе рәисе **Плеханов** Сергей Александрович; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Чирәмдә хоккей үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Ратников** Александр Федорович; мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Сафиуллина** Вәсилә Гарәфетдин кызы; татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Хәррасова** Рифә Фәтхерахман кызы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы урынбасары – Идарәнең оештыру-беркетмә бүлеге мөдире **Яруллин** Салават Мөнир улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен **Хафизов** Мансур Гаптрахман улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Зилант» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Абдрахманов** Ришат Мөхтәсиб улы; Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесенең филология кафедрасы доценты **Галиева** Миләүшә Заһит кызы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Тимерхан Бизнес» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кейтеринг менеджеры **Сабиров** Дамир Рафаил улы, «Тимерхан Бизнес» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кейтеринг менеджеры **Хаммадиев** Салават Минзәки улы; конфессияара татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Әлмәт Епархиясе» дини оешмасының социаль бүлеге җитәкчесе **Петряев** Константин Петрович; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Таҗетдинов** Ринат Арифҗан улы, Казан шәһәренең «Мирный торак массивындагы мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе клуб формированиесе җитәкчесе **Миронов** Илнар Илфир улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Казан шәһәренең «О.Л. Лундстрем исемендәге 16 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең тынлы уен кораллары укытучысы **Артемьев** Александр Тимофеевичка, «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш администраторы **Бәшәрова** Зөлфия Фәргать кызына, Чаллы шәһәренең «Мастеровые» рус драма театры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе директоры **Диамантэ** Армандо Луиджиевичка, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «6 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Калинина** Людмила Анатольевнага, «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе концертмейстеры **Карпова** Алсу Ринат кызына, «Казан шәһәренең үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры урынбасары **Лепихина** Венера Фәнилиринат кызына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Авылара үзәк китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең методика бүлеге мөдире **Липина** Марсельеза Әкъмәлетдин кызына, Татарстан Республикасының «Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Шакиров** Зөфәр Гомәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге Әгерҗе районындагы клиентлар белән эшләү хезмәте (бүлек хокукында) җитәкчесе **Бакасова** Зөлфия Шамил кызына; Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәсе башлыгы урынбасары – пенсия билгеләүне һәм яңадан исәпләүне оештыру бүлеге башлыгы **Львова** Ирина Александровнага; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районындагы «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсе социаль эш буенча белгече **Булатова** Эльмира Илдар кызына; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы «Доверие-Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль хезмәткәре **Мусина** Гөлнур Камил кызына; Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге социаль иминияткә чыгымнарны планлаштыру бүлеге башлыгы урынбасары **Зариева** Миләүшә Флюр кызына; Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге бурычлар белән эшләү 7 номерлы бүлеге әйдәүче белгече-эксперты **Яппарова** Сәлимә Габделбарый кызына; Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге бурычлар белән эшләү 12 номерлы бүлеге башлыгы **Ярмушев** Рамил Наил улына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТЫНГЫСЫЗ ЙӨРӘК

tatarstan.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Геройларча хезмәт

Кеше китә – җыры кала, дигәндәй, министрның кыска гына гомерендә башкарган эшләре санап бетергесез. Мәрхүм турында хатирәләрне яңартканда сүзнең башы әнә шул хезмәтләрне барлауга барып тоташты.

Президент Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, ул, иң беренче чиратта, үз эшенә чын күңелдән бирелгән сәләтле табиб иде.

– Марат бик ышанычлы һәм төгәл кеше иде. Пандемия республика сәламәтлек саклау системасының ничек оештырылуын күрсәтте. Туганнары һәм якыннарының кайгысын чын күңелдән уртаклашам. Бу – зур югалту. Аны беркайчан да онытмаячакбыз, – диде Президент хушлашу мәрасимендә.

Коллегасы белән хушлашу өчен Казанга махсус килгән Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко министрлык вазыйфасында аңа шактый сыналырга туры килүен дә билгеләп үтте.

– Коронавирус башлануга, әлеге чирне йоктырган иң беренче кешеләрне Казанга алып кайттылар. Марат Садыйков гел элемтәдә булды. Аның сүзләре һәрчак ышаныч уятты. Иң катлаулы очракларда да: «Булдырабыз, барысын да эшлибез», – дип әйтә иде. Мин бу кешене бик нык хөрмәт итәм, аның алдында баш иям, – диде министр ничек борчылганын һәм кайгырганын яшерә алмыйча.

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев министрны, тынгысыз йөрәк, дип искә алды.

– Соңгы еллар бик катлаулы булды. Алар Марат Садыйковның сәламәтлегенә дә йогынты ясады, билгеле. Мондый тынгысыз елларда без гел борчылып торабыз икән, медицинадагы беренче затка ни эшләргә кала? Аның тормышы шундый иде. Язмыш… Хезмәтең өчен зур рәхмәт! Ул геройларча булды. Авыр туфрагың җиңел булсын! Сүз юк. Бик нык кайгырабыз. Син безнең хәтердә мәңгегә калачаксың. Авыр вакытларны болай гына онытам димә. Ә ул чорда нәкъ менә син ярдәм иттең. Без сине онытмаячакбыз, онытырга ярамый да. Безнең халык өчен зур югалту бу, – диде Минтимер Шәймиев.

Коронавирус котырган чорда Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе Марина Патяшинага Марат Садыйков белән иңне иңгә куеп эшләргә туры килде. Кимчелекләрне вакытында төзәтеп, җитешсезлекләрне тиз арада юкка чыгарырга тырышкан ул.

– Нинди генә гозер белән мөрәҗәгать итсәң дә, һәрчак игътибар белән тыңлый, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша иде. Үз бурычын башкаларга йөкләмәде. Кешеләргә чын күңелдән ярдәм итә иде. Ул искиткеч әти һәм ир дә иде, балалары турында һәрчак яратып сөйләде. Гаиләсе өчен җан атып торды. Без аны беркайчан да онытмаячакбыз, – диде Патяшина.

Оясында ни күрсә…

Табиб хезмәттәшләре аны үзенә һәм аның җитәкчелегендә эшләүчеләргә карата таләпчән, кешеләрне иң югары профессиональ дәрәҗәгә күтәрә белүче җитәкче иде дип искә ала. РКБның баш табибы Рафаэль Шәвәлиев мәрхүм турында сөйләгәндә күз яшьләрен тыеп кала алмады.

– Аның турында үткән заманда сөйләү, мәңгелеккә китүен аңлау бик кыен. Сәләтле лидер, остаз һәм бик яхшы дус иде ул. Эшкә бөтен күңелен, бар вакытын бирде, гел нидер эшләргә ашыкты. Аның бик зур максатлары бар иде. Ул безнең һәркайсыбыз өчен никадәр эш башкарды. Күпме башкарасы эше калды… Марат Наил улы, авыр туфрагың җиңел, урының оҗмахта булсын. Бик зур рәхмәт сиңа, – дип бәхилләште баш табиб.

Марат Садыйков – данлыклы табиблар нәселеннән. Әтисе – Наил Садыйков – Россиянең атказанган табибы. Әле бу көннәрдә генә Марат Садыйковның улы Марсель дә КФУның прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәгенең баш табибы итеп билгеләнгән иде. Министр үзе хезмәт юлын Казанның 18 нче номерлы шәһәр хастаханәсендә баш табиб урынбасары вазыйфасында башлаган. Ул елларда әлеге хастаханәдә баш табиб булып эшләгән Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы Рөстәм Бакиров Марат Садыйков белән бергә эшләгән елларын бик сагынып искә алды.

– Әле һаман аңлап та, ышанып та бетерә алмыйм. 1996 елдан башлап ул минем урынбасар булып эшләде. Без аның белән шулкадәр килешеп, рәхәт эшләдек. Яшьрәк булса да, аның белән бик җайлы иде. Аның белән киңәшләшергә дә рәхәт иде. Табиблар династиясендә үскән егет шул. Аның дуслар – минеке, минем дуслар аныкына әверелде. Ул 18 нче хастаханәне көчәйтергә бик нык ярдәм итте, – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә Рөстәм Бакиров.

Үзе китә, эзе кала

Биредә дүрт ел эшләгәннән соң, сигез ел Республика онкологик диспансерының баш табибы вазыйфасын башкара ул. 2008 елдан башлап исә республиканың иң зур дәвалау оешмаларының берсе саналган 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе белән җитәкчелек итә Марат Садыйков. Министр турында кем белән генә сөйләшмә, һәркем республика тармагында башкарган иң зур эшләренең берсе дип аның әлеге хастаханәне бөтенләй яңа дәрәҗәгә чыгаруын атый. Бүген ул республиканың иң заманча җиһаз һәм технологияләр кулланып эш иткән алдынгы дәвалау оешмасы санала. Хастаханәнең ашыгыч медицина үзәге 2013 елда узган Халыкара җәйге Универсиаданың госпитальләре рәтенә керде.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов фикеренчә, ул чакта 7 нче номерлы хастаханә баш табибы итеп нәкъ менә Марат Садыйковның билгеләнүе юкка түгел.

– Ул һәрчак ачык, позитив булды. Кешеләр белән шулкадәр тиз уртак тел таба, сөйләшә белә иде. Ул җитәкчелек иткән чорда хастаханәдә өч төрле коллективны бер түбә астына җыю бурычы тора иде. Бу – бик авыр эш. Әмма моны башкарып чыга алды. Аның үлеме – республика, сәламәтлек саклау тармагы өчен зур югалту. Без бик дус идек. Аның турында якты хатирәләр йөрәгемдә мәңге сакланачак, – ди Айрат Фәррахов.

Сүз уңаеннан, Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсенә Марат Садыйков исемен бирергә тәкъдим итте. «Ниндидер даталар көтмичә, моны хәзер үк эшләргә кирәк», – дип язган ул «Телеграм»дагы каналында.

ДРКБның баш табибы Айрат Зыятдинов министрның республикада балаларга медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә дә зур эшләр башкаруын искәртте. Аның җитәкчелегендә заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән балалар онкология үзәге сафка басуны бу юнәлештә башкарылган иң саллы хезмәтләрнең берсе дип саный ул. Мондагы шартлар моңа кадәр табиблар алынырга курыккан иң җитди операцияләрне дә ясарга мөмкинлек бирә.

– Үз эшенең остасы, көчле җитәкче. Язмыш көн дә китереп торган сынауларны бирешмичә, уңышлы гына җиңеп яшәде. Әти-әнисе өчен игелекле ул, ярата белүче ата, ышанычлы гаилә башлыгы булуы белән дә игътибарга лаек иде ул. Тормыш иптәше белән шундый тәртипле, тәрбияле балалар үстерделәр, – ди табиб.

Марат Садыйков Казан читендәге Тынычлык бистәсе зиратына җирләнде. Аны кабергә иңдергән мәлдә, буранлап, ишеп-ишеп кар яварга тотынды. Гүя табигать тә фидакарь табибның гомере вакытсыз өзелгәнгә көрсенә, каберенә дә кар түгел, ә табиблар символына әверелгән ак чәчәкләр яудыра иде…

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

САДЫЙКОВ МАРАТ НАИЛ УЛЫ

(27.01.1970 – 29.01.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры Садыйков Марат Наил улы 29 гыйнвар көнне 54 нче яшендә кинәт кенә арабыздан мәңгегә китте.

Марат Садыйков 1970 елның 27 гыйнварында ТАССР Буа шәһәрендә дөньяга килгән. 1993 елда Казан дәүләт медицина институтының педиатрия факультетын тәмамлаганнан соң, хезмәт эшчәнлеген Казан шәһәре Республика медицина диагностика үзәгендә балалар табибы вазыйфасында башлап җибәргән.

1993–1995 елларда Казан дәүләт медицина институтының педиатрия кафедрасында клиник ординатурада белем алган. 1996–2000 елларда Казанның Идел буе районы 18 нче шәһәр клиник хастаханәсе консультатив-диагностика үзәгендә баш табиб урынбасары булып эшләде. 2000–2018 елларда республика башкаласының зур медицина оешмасына – «Онкология» шәһәр махсус медицина берләшмәсенә, 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенә җитәкчелек итте.

Марат Наил улы 2018 елда Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры вазыйфасына билгеләнде. Ул үзенең бөтен һөнәри тәҗрибәсен, белемен республика сәламәтлек саклау өлкәсен ныгыту һәм яңартуга юнәлтте. Федераль һәм республика программалары уңышлы тормышка ашырылды, югары технологияле яңа медицина үзәкләре ачылды, авыл җирлегендә фельдшер-акушерлык пунктлары челтәре киңәйтелде. Шул ук вакытта медицина хезмәтләре цифрлаштырылды. Ул үзенең эшчәнлегендә Татарстанда яшәүчеләрнең барчасына медицина ярдәменең сыйфатлы һәм үзвакытында күрсәтелүен даими игътибар үзәгендә тотты.

Аның тырышлыгы, шулай ук медицина хезмәткәрләренең, медицина продукциясе җитештерүчеләрнең, төзүчеләр, волонтерлар һәм башка җаваплы кешеләрнең оешкан уртак эше нәтиҗәсендә соңгы елларның төп сынавы – COVID-19 пандемиясенең аянычлы нәтиҗәләреннән котылуга ирешелде.

Марат Садыйков IV һәм V чакырылышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты итеп сайланды.

Марат Наил улының нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри уңышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Болар – «Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «Татарстан Республикасының атказанган табибы» мактаулы исеме, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе, «Сәламәтлек саклау отличнигы» күкрәккә тагу билгесе.

Марат Садыйков үзен югары квалификацияле, җаваплы, абруйлы җитәкче һәм талантлы табиб буларак күрсәтте. Югары дәрәҗәдәге эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге, иҗтимагый бурычка тугрылыклыгы һәм кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәте аңа зур абруй һәм хөрмәт китерде.

Марат Наил улы Садыйковның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, А.З. ФӘРРАХОВ, Л.Р. ФАЗЛЫЕВА, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, И.Р. МЕТШИН, Р.Р. КАМАРТДИНОВ, А.С. СОЗИНОВ, Ч.У. МӘХМҮТОВ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, IV–V чакырылыш (2009–2019 еллар) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коллективы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, гаиләсе, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу авыр көннәрдә сезгә сабырлык бирсен.

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

кинәт вафат булуы барыбызны да тетрәндерде.

Олы йөрәкле табиб, талантлы оештыручы, үз сүзендә нык торучан, коллегалары, гади халык арасында зур абруй-хөрмәт яулаган шәхес арабыздан мәңгегә китте. Ул бигрәк тә медицина өчен авыр булган соңгы 5 елда республиканың сәламәтлек саклау өлкәсен үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертте. Министрлык вазыйфасында тагын бик күпне эшли алган булыр иде. Бөтен республика өчен гаять зур югалту… Мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз. Бу авыр көннәрдә аларга сабырлык һәм ныклык телибез.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов.

Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы Советы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) Советының иҗтимагый комиссия рәисе, әтисе Садыйков Наил Сәләх улының, тормыш иптәше, балалары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын, гаиләсенә һәм якыннарына Ходай сабырлык бирсен.

ТАИФ компанияләре төркеме коллективы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Марат Наил улының якты истәлеге, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау өлкәсенә бәһаләп бетергесез өлеш керткән талантлы җитәкче, үз эшенең чын остасы, гүзәл кеше буларак, күңелләребездә мәңгегә сакланачак.

Спас муниципаль районы советы, башкарма комитеты, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Республика инкассациясе идарәсе, Вахитовлар гаиләсе, абруйлы җитәкче, игелекле һөнәргә чын күңелдән бирелгән талантлы табиб, Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ Марат Наил улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең тормыш иптәше Динара Илгизәр кызының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша һәм сабырлык тели. Бу – бөтен республикабыз өчен зур югалту. Марат Наил улының урыны җәннәттә, авыр туфрагы җиңел булсын!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, ире

ГАЙНУЛЛИН Гомәр Рәүф улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Җаббарова Роза Шәрифулла кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы мелиораторлар коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, элекке РСФСР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы «Татмелиоводстрой» махсус тресты идарәчесенең тәэминат буенча урынбасары

САФИН Әсхәт Идрис улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы мелиораторлар коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, «Мелиорация» Бөгелмә механикалаштырылган күчмә колоннасы ачык акционерлык җәмгыяте элекке генераль директоры

БАКИРОВ Рәшит Баһман улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

БЕР МИНУТТА – МЕҢ СҮЗ

КФУ СТУДЕНТЫ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТИЗ УКЫРГА ӨЙРӘТӘ

Минутына 150–250 сүз укыган кеше бу санны 650–1200гә дә җиткерә ала. КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты Мәликә ХӘЙРУЛЛА татар телендә тиз уку курсы әзерләгән. Тиз уку методикасы нидән гыйбарәт? Әлеге курс кемнәр өчен? Мәликә белән шулар турында сөйләштек.

Мәликәнең татар телендә тиз уку курсы – Россиядә әлегә берданбер. Дүртенче курс студентының «Тиз уку» проекты КФУның «Ел студенты – 2022» бәйгесенең «Иң яхшы студент инициативасы» номинациясендә дә җиңгән.

– Мин мәктәптә укыган чакта ук тиз укырга өйрәнергә хыялланa идем. Университетка укырга кергәч, моның белән ныклап шөгыльләнә башладым. Моңарчы татар телендә тиз уку курслары бөтенләй юк иде. Филология бүлеге студентлары буларак, без университетта бик күп әсәрләр укыйбыз, ә вакытыбыз чикле. Фәнни җитәкчем янына килеп, тиз уку юнәлешен татарча өйрәнергә тәкъдим иттем. Теорияне рус һәм инглиз телләрендә, практиканы татар әсәрләре нигезендә өйрәндем. Татар теленең лексик, морфологик, синтаксик һәм психологик үзенчәлекләрен аердык, – ди Мәликә. – Минем бер кагыйдәм бар: үзең өйрәнгәч, башкаларны да өйрәт. Шулай миндә курс уздыру фикере туды. Үткәреп карадым, уңышлы гына килеп чыкты. Бүген мин фәнни тикшеренүләрне дәвам итәм. Киләчәктә укытуны да дәвам итәргә ниятлим.

Мәликә әйтүенчә, тиз уку өчен тел үзенчәлекләренә туры килә торган текстлар төзергә һәм сайларга кирәк.

– Курс теория һәм практик өлештән тора. Тиз укуга өйрәнгәндә кешенең физиологик һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк. Күнегүләр дә шуларны исәпкә ала. Физиологияне яхшырта торган күнегүләрдән күзләр йөртү, кул хәрәкәтләрен атарга мөмкин. Психологик үзенчәлекләргә аң белән эшли торган күнегүләр кирә. Моның өчен махсус текстлар әзерләдем, кайберләрен тәрҗемә иттем, кайберләрен матур әдәбияттан таптым. Алар күнегүләрнең максатына да туры килә, татар теленең үзенчәлекләрен дә исәпкә ала, – ди студент кыз.

Узган елның җәендә Мәликә үз методикасын сынау өчен татар телендә тиз уку курсын уздырып караган. Аның әйтүенчә, нәтиҗәләр буенча бу чорда укучыларның уку тизлеге уртача 150–250 сүздән 650–1200 сүзгә кадәр арткан. Мәгълүматны да алар ике-өч тапкыр тизрәк үзләштерә башлаган.

– Вакыт буенча курс уртача 6 атна дәвам итә. Кешенең үзенә генә хас үзенчәлекләрен, максатларын исәпкә алып, бу вакыт үзгәрә ала. Һәр кеше материалны төрлечә кабул итә бит. Ниндидер сүзләрне тизрәк укырга өйрәнә, кайсыларындыр авыррак үзләштерә. Курс барышында укучылар белән кайбер күнегүләрне үзгәртәбез. Кемгә нәрсә кирәк, шуларга басым ясарга тырышабыз, – ди Мәликә.

Татар телендә тиз уку буенча курс – бушлай. Тик шартлары бар: 14 яшьтән өлкәнрәк булу һәм татар телен белү.

– Курс бушлай, чөнки минем өчен иң файдалы әйбер ул – мәгълүмат. Курска килүчеләр өчен татар телен белү дә шарт, чөнки без телгә өйрәнмибез, без татар телендә тиз укырга өйрәнәбез. Тиз укуның асылы – эчке тавыштан арынуда. Укыганда без, гадәттә, эчтән әйтеп барабыз, ә тиз укырга өйрәнгәндә ул тавышны «сүндерәбез». Сүзне хәрефләр җыелмасыннан гына аңларга өйрәнергә кирәк. Моңа, билгеле, телне белүче генә өйрәнә ала, – ди Мәликә Хәйрулла.

Тиз уку белән төрле һөнәр ияләре кызыксына икән.

– Курс күбрәк филологлар өчен кызыклы булыр дигән идем, алай гына булмады. Укучыларым арасында микробиолог та, скрипкада уйнаучы кыз да, инженерлар да бар. Курс һәркем өчен файдалы. Тиз уку фәнни текстлар үзләштергәндә дә, ноталар укыганда да ярдәм итә. Хәзерге заманда тиз уку – бик кирәкле һәм файдалы күнекмә.

Мәликәнең алга таба да планнары зурдан:

– Тиз уку буенча курсны киңрәк аудиториягә җиткерәсем килә. Әлегә мин татар телле мохиттә яшәүче кешеләр белән эшлим. Тиз уку аларда зур кызыксыну уятты һәм мин моңа бик сөенәм. Киләчәктә, бәлки, чит илдә яшәүче кешеләр белән дә эшләп булыр, – ди ул.

Ләйсән САФИНА

Спорт

ak-bars.ru

Тәртипле хоккей

«Ак барс» бу сезондагы иң зур җиңүен яулады. «Трактор» капкасына 6 җавапсыз алка керткән Казан хоккейчылары Көнчыгыш конференциясендә – икенче урында. Әлеге җиңүдә иң зур өлешне моңарчы нык тәнкыйтьләнгән уенчылар кертте. Вадим Шипачевның инде 20 матч буе уңышка ирешә алганы юк иде.

Казан командасы февральгә кергәндә Көнчыгыш конференциясенең лидерларыннан берсенә әверелде. Бу сүзне сезон башында әйткән булсалар, беркем дә гаҗәпләнмәс иде. Әмма «Ак барс»ка октябрь һәм ноябрьдә моңарчы күрелмәгән сынаулар аша узарга туры килде. Хәтта команданың плэй-оффка эләгәсенә шик белдерүчеләр дә табылды. Ә аннары Зиннәтулла Билалетдинов кайтты. Дөресрәге, чакырырга мәҗбүр булдылар.

Тырышкан булдырыр! Уенчыларына әнә шул фәлсәфәне сеңдерүче остаз тырыша торгач, ике ай эчендә «Ак барс»ны, сүтеп, яңадан җыя алды. Гыйнварда узган 12 очрашуда Казан командасы 10 җиңү яулады. Хәтта җиңелү белән тәмамланган ике уенда да якташларыбыз берәр очкога ия булды. Безнекеләр беренче баскычтагы «Себер»дән уенның төп вакытында җиңүләр саны буенча гына калыша.

Билалетдиновның мантыйгы билгеле: башта тәртип, аннары нәтиҗә. Тәҗрибәле остаз әнә шуның аша командасын астан өскә күтәрә алды. Дөрес, бүгенге «Ак барс»ның уенын кызыксыз дип атаучылар да бар. Әмма төп максат – җиңү. Команда исә моңа ничек ирешәсен яхшы белә. Кызык хоккейны исә якшәмбе көнне «Трактор»га каршы уенда күрсәттеләр.

«Ак барс»та хәзер һәркем ни эшлисен яхшы чамалый. Уенчылар яшерми: аларга бозда ни эшләргә кирәклеген җентекләп аңлаталар. Күз көне командадан ызгыш, тарткалаш турында хәбәр килсә, хәзер тынычлык хөкем сөрә. Баш тренер яңа килгән уенчылар, элеккегеләр һәм яшьләрне укмаштырып, Гагарин Кубогы өчен көрәшә алырлык көч туплый алды. Александр Радулов чын капитанга әверелде, Станислав Галиев белән Вячеслав Войнов – күплектә алыштыргысыз уенчылар, Никита Сафонов белән Дмитрий Воронковтан көч ташып тора, Артем Лукоянов, Михаил Глухов һәм Василий Токрановның да кирәге чыкты, ә Тимур Билалов – төп капкачы. Соңгы арада Вадим Шипачев белән аның янәшәсендә уйнаган егетләрне еш телгә алдылар. Соңгы елларда Россия хоккеенда иң нәтиҗәле һөҗүмче булып танылган уенчының инде 20 матч дәвамында алка кертә алганы юк иде. «Трактор»га каршы узган уенда исә Шипачев, Дмитрий Кагарлицкий һәм Кирилл Петров өчесенә 10 очко җыйдылар. «Алар һәрвакыт яхшы уйнады. Монда гаҗәпләнерлек берни юк», – диде Зиннәтулла Билалетдинов.

Плэй-оффка кадәр «Ак барс»ның тагын 11 матч уздырасы калды. Шул исәптән СКА белән очрашасы, Ерак Көнчыгышка барып, «Адмирал» һәм «Амур» белән икешәр мәртәбә көч сынашасы, Казан бозында «Металлург» һәм «Авангард»ны кабул итәсе бар. Турнир таблицасына күз салсак, Көнчыгыш конференциясендә беренче һәм алтынчы команда арасында нибары 5 очко аерма барлыгын күрәбез. Урыннары көн саен үзгәреп тора. Кыскасы, инде хәзердән үк плэй-офф рухы хөкем сөрә. Өстә генә түгел, аста да шул ук хәл. Берьюлы 4 команда сигезенче урын өчен көрәшә. Араларында «Нефтехимик» та бар. Димәк, «Ак барс» үзенә очко җыю гына түгел, Түбән Камадагы якташларыбызга да ярдәм итү мөмкинлеге булачак. 7 февральдә алар Казан бозында бер-берсенә каршы чыгачак.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

	команда	уен	очко
1	Сибирь	57	73
2	Ак барс	57	73
3	Автомобилист	56	72
4	Металлург	56	70
5	С. Юлаев	57	69
6	Авангард	55	68
7	Адмирал	56	63
8	Нефтехимик	57	57
9	Барыс	59	57
10	Амур	55	56
11	Трактор	57	54

Гаҗәп түгел: бүген әбиләрдән алып бәбиләргә кадәр кулдан телефон төшерми. Интернеттан башка яшәешне күз алдына да китермибез кебек. Белгечләр исә чама хисен югалтмаска киңәш итә. Заманасына күрә – чире дигәндәй, «Интернетсыз бер көн» халыкара датасын да уйлап тапканнар хәтта. Менә шундый бәйрәм! Интернеттан башка тормыш бармы? Без әнә шул сораунга җавап эзләдек.

cadelta.ru

«ПӘРӘВЕЗ»ЛЕ ТОРМЫШ

Әйтергә кирәк, «дөнья пәрәвезе» яшәешебезне күпкә җиңеләйтте. Бүген суыткычны тутыру өчен кибеткә барып торасы юк. Кесә телефонында азык-төлек кибете кушымтасына кереп, интернет кәрҗинеңне барлыйсың да, бер сәгать эчендә бөтен кирәк-яракны алып килеп бирәләр. Ут-суга түләү, баланың мәктәптә алган билгеләрен тикшерү өчен дә кулдагы телефон җитә. Интернет мәгълүмат туплау чыганагы булудан бигрәк, күңел ачу, аралашу мәйданына әверелде. Бөтенроссия халык фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, илдә яшәүчеләрнең 81 проценты «дөнья пәрәвезе»ннән файдалана. Алай гына да түгел, респондентларның 69 проценты: «Интернетка көн саен керәм», – дип белдергән. Шуңа күрә дә белгечләр чаң суга! Мондый бәйлелек куркыныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин, диләр. Дөрес, әлегә бу медицина өлкәсендә расланган диагноз түгел. Тик дөньяның кая таба барганы көн кебек ачык.

«Интернетсыз бер көн»не шуңа күрә уйлап тапканнар да инде. Ул дөнья күләмендә 2000 нче еллардан бирле билгеләп үтелә. Бәйрәмнең тәгаен көне юк, аны гыйнварның соңгы якшәмбесендә бәйрәм итәләр. Димәк, бу көннәрдә утырып уйлану бик урынлы. Оештыручылар шуны да искәртә: интернетта утыру белән кесә телефонын аралашу өчен файдалануны бутарга ярамый.

Татарстанның Тукай районы Кырныш авылында яшәүчеләрнең исә бәйрәм итәрлек кәефе юк. Салада интернет тотмый. Былтыр Россиядә кечкенә торак пунктларны мобиль интернетка тоташтыруга бәйле федераль проект эшли башлады. Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәгълүматларына караганда, былтыр республикада 624 шундый авыл теркәлгән. Аларга 4G интернет 2030 елга кадәр барып җитәчәк, дип фаразлана. Программа әнә шул вакытка кадәр исәпләнгән. Кечкенә авылларны интернетлы итү өчен федераль бюджеттан 1,6 миллиард сум акча тотылачак. Кырныш авылында яшәүчеләр дә үз чиратын көтә.

– Интернет булмау мәсьәләсе быел узган халык җыенында да күтәрелде, – ди Калмия (Кырныш авылы шушы җирлеккә керә. – **Ред.**) җирле үзидарәсе җитәкчесе урынбасары Мөхәммәтдинова Розалия. – Элек Кырныш гел беткән иде, бүген исә яңа үсеп килә торган зур авыл ул. Анда 700гә якын җир кишәрлеге һәм йорт бар. Пропискада булучылар гына азрак. Илкүләм программада катнашу өчен Дәүләт хезмәтләре порталында тавыш бирү оештырылды. Исемлеккә без дә эләктек. Халык интернет килеп җиткәнне бик көтә. Балалар бакчасы һәм мәктәп Калмия авылында урнашкан. Биредә уку өчен бөтен мөмкинлекләр, шул исәптән интернет та бар. Хәзерге заманда «дөнья пәрәвезе»ннән башка булмый. Халык бик көтә.

Узган ел мобиль операторларның берсе Татарстанда интернеттан иң күп файдаланучы авыллар исемлеген дә төзегән иде. Белгечләр теге яки бу торак пунктта яшәүче кеше башына күпме интернет-трафик туры килүен исәпләгән. Беренче урында – Югары Осланның Введенская Слобода авылы. Эшнең нидә икәнен аңлау өчен, бу сала Иннополис янәшәсендә урнашкан, дип әйтү дә җитәдер. Икенче урында – Әлмәт районының Түбән Мактама авылы. Беренче өчлеккә Лаеш районының Зур Кабан авылы да эләккән. Бер елда Мөслим, Кайбыч һәм Яңа Чишмә районы халкы интернеттан күбрәк файдалана башлаган.

Аш-су остасы, блогер Гөлия Шәйхетдинова интернеттан башка тормышны күз алдына да китерми.

– Декретка чыккач, аш-су әзерләү белән шөгыльләнә башладым. Кайнар ризыклар, чәй табынына тәм-том пешерәм. Әзер ризыкларны социаль челтәргә урнаштырып барам. Интернет кына эшләп торсын. Бөтен гомерем шунда. Сәхифәмдә 30 меңгә якын язылучым бар. Аларны югалтмас өчен шәхси тормышымны да күрсәтергә туры килә, әлбәттә. Интернетта көненә уртача 3–4 сәгать утырам. Аена 20–25 мең сум акча эшлим, – ди блогер.

Татарстанның атказанган артисты Эмиль Талиповны исә социаль челтәрләрдә табып булмый.

– Бүген һәркем нәрсә ашаганын, нәрсә кигәнен, кая баруын – барысын да интернетка куярга тырыша. Бу нәрсәгә кирәк? Моннан кызык тапмыйм. Социаль челтәрләрдә утырырга вакытым да, теләгем дә юк. Берәр яхшы фильм карасаң, китап укысаң, күпкә яхшырак. Сәнгать кешесе буларак, кешеләрне, табигатьне күзәтергә яратам. Телефон аша түгел. Ә үз күзләрең белән күрергә, тоемларга кирәк. Шулчак төрле фикерләр килә. Гомумән, дөньяны ишетә белү мөһим. Югыйсә хәзер кешеләр бер-берсен күрми дә бит. Дуслар, кунаклар җыелган җирдә дә бөтенесе телефонга төбәлеп утыра. Без күптән аралашмыйбыз, күзгә-күз карашып сөйләшмибез. Интернет аралашуны алмаштырды. Игътибар итсәгез, «дөнья пәрәвезе» кешене «йота». Мавыгып китеп, интернетка әллә ниләр чыгара башлыйлар. Чик-чама хисе югала. Ә бу бер дә матур күренеш түгел. Бигрәк тә сәхнә кешеләренә килешми. Син кеше күз алдында икән, тәрбияле була белергә дә тиеш. Чөнки сине хөрмәт итеп күзәтәләр, әйткән сүзеңә колак салалар. Һәрнәрсәнең алтын уртасы булырга тиеш, дип саныйм. Интернеттан үземә эшкә кирәкле мәгълүматлар гына алырга тырышам. Әгәр теләсә нәрсә карап утырсаң, дөньяның пычраклыгына шаккатасың. Элек интернетсыз да яшәгәнбез бит. Әлбәттә, хәзер дөнья алга таба бара. Ләкин кемнең нәрсә ашавы кемгә кирәк?

Психолог Венера Касыймова әйтүенчә, интернетта утырырга яратучылардан еш кына: «Мин «дөнья пәрәвезе»ндә үткәргән вакытны контрольдә тотам», – дигән сүзләр ишетергә туры килә.

– Юк, без интернет белән түгел, ә ул безнең белән идарә итә, – ди белгеч. – Элек гаиләдә телевизордан кайсы каналны карыйбыз дип, пульт өчен тарткалашсалар, хәзер шымнары да чыкмый. Чөнки һәркемнең кулында – телефон. Аның каравы бер-береңне ишетү, аңлау кебек гаилә өчен бик тә кирәкле сыйфатлар югала. Буш вакыт чыккан саен «дөнья пәрәвезе»нә кызыгып кесә телефонына үреләсез икән, димәк, сездә бәйлелекнең җиңел формасы бар. «Интернетсыз бер көн» – сәламәтлегегезне тикшереп карау өчен менә дигән мөмкинлек. Хәер, моның өчен аерым бәйрәм дә кирәкми.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИНТЕРНЕТКА НИ ӨЧЕН КЕРӘСЕЗ? *(Иң еш сайланган җаваплар)*

Якыннарым, туганнарым белән аралашам	**88%**
Яңалыклар карыйм	**83%**
Күңел ачам, уйныйм	**75%**
Кирәк-ярак сатып алам	**50%**

(ВЦИОМ үткәргән сораштырудан)

КЕМ КӨЧЛЕРӘК?

КАРИЕВ ТЕАТРЫНДА – НАРКОТИКЛАРГА БӘЙЛЕЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШ КЫЙССАСЫ

Премьера

Көчсезлекне күрсәтергә көч кирәк. Бәйлелеккә каршы көрәшкәндә дә иң авыр адым – бәйлелектә булуыңны тану. Кариев театрындагы чираттагы премьера наркотикларның кеше тормышын ничек итеп җимерүен һәм аңа каршы торуның ни дәрәҗәдә авыр булуын күрсәтте. «12 адым» гына кебек, ә асылда...

vk.com/kariev_teatri

...физик кына түгел, ә рухи һәм әхлакый яктан да «җимерелгән» шәхесне яңадан «җыю»ны сәхнәдән күрсәтү – шактый катлаулы нәрсә бит. Тамашачың яшь булса, бигрәк тә. Кариев театры документальлек юлыннан киткән һәм сюжет сызыгын эчкечелек һәм наркотикларга бәйлелекне дәвалауда кулланыла торган «12 адым» программасына «үргән». Спектакль үзе дә «12 адым» дип атала.

– Әминә (режиссеры Әминә Миндияр. – **Авт.**) үзе дә, артистлар да реабилитация узган бәйле кешеләр белән очрашты, хәзерге вакытта наркоманиядән котылу программасы буенча дәвалана торган кызлар-егетләр белән аралашты, «12 адым» вәкилләре белән эшләде. Зарарлы матдәләрнең җирәнгеч якларын күрсәтә торган спектакль чыгару театр өчен дә – зур стресс, – дигән иде Кариев театры директоры Луиза Шарова.

Яшьләр ни өчен наркотикларга сузыла соң? Бу очракта рәхәтлеккә чыдый алмаганга күрә. Төп герой – бик бай гаиләдә үскән, әти-әнисе игътибары урынына акча белән алданган Камил (Рамил Вафин һәм Илсаф Нәҗипов).

– Ата кеше – бизнесмен. Балага игътибарлары җитми калган. Эш белән мәшгуль булып, бөтен «каприз»ларын үтәп, баланың шундый юлга кереп китүен сизмәгәннәр. Спектакльдәге төп мәгънә: әгәр бала бәйле кешегә әйләнгән икән, аны гына түгел, бөтен гаиләне дәваларга кирәк. Бу – бөтен гаиләнең проблемасы, – ди Камилнең әтисен уйнаучы Фәнис Кәлимуллин.

Камилнең йөргән кызы бар. Алинә (Рузанна Хәбибуллина) шулай ук бай гаиләдә тәрбияләнгән булса кирәк. Әти-әнисе Алинәдән «гений» ясамакчы. Наркотик татып карауның беренче сәбәбе рәхәтлек булса, икенчесе – үзенә күрә баш күтәрү. Өченче герой Артурны Муса Камалов уйный. Ул – башкаларга иярүче, хәтта дусларын туктатырга да тырышып карауча персонаж. «Безнең бит барысы да бар. Нәрсә җитми безгә тагын, ә?!», «Мине менә нәрсә борчый: без бит аннары туктый алачакбыз?» – Артурның сүзләре.

Өч дусның наркотиклы тормышы бары караңгы төсләрдә генә күрсәтелгән. Тора-бара яшьлекнең иң матур чорын кичерүче үсмерләрнең йөзендәге нур юкка чыга, ачык төстәге киемнәрен сәләмәләр алыштыра. Наркотик сатып алырга акчасы беткәч, Алинә фахишәлек юлына баса. Һәм бу «сазлык»тан бары Камил генә чыгу юлын таба...

Рольләргә килгәндә, киенү, сөйләшү рәвешләре һәм үз-үзләрен тотышлары белән алар чит ил фильмнары геройларын искә төшерде. Бәлки, шул фильмнарга мөкиббән булган яшь тамашачыларына ярарга тырышулары булгандыр. Алар үзләре ни уйлый соң? 9 нчы сыйныф укучысы Зәринә Әюпованың фикерен белештек.

– Спектакль бик ошады. Миңа калса, бу ситуациянең ни дәрәҗәдә трагедияле булуын күрсәтә алганнар. Аеруча наркотикларга кадәрге бәхетле тормыш һәм алардан соңгы газапларны капма-каршы куеп күрсәтүләре ошады, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белгеч фикере

Миләүшә ШӘМСЕМӨХӘММӘТОВА, психолог:
– «12 адым» программасы – коткаручы маяк ул. Аңа кадәр бәйлелеге булган кешеләргә ярдәм итү чаралары бөтенләй булмаган. Минем дә тормышның төбенә төшкән кешеләр белән эшләү тәҗрибәм бар. Бу программа аларга янәдән үзләрен кулга алырга, көчсезлекләрен танырга һәм көч тупларга ярдәм итә. Спектакль исә тыелган матдәләрне рәхәтлек алу өчен генә куллануны да, аларның кеше тормышын бөтенләе белән җимерүен дә, дәвалану процессын да күрсәтә. Гаять зур эш башкарылган. Тамашачыга барысын да ничек бар – шулай күрсәтү, аларны бу упкыннан да чыгу юлы барлыгына ышандыру – катлаулы нәрсә. Дөресен генә әйткәндә, без барыбыз да күпмедер дәрәҗәдә бәйлелек кичерәбез. Кешеләрдән, тормыш иптәшебездән, эштән, акчадан... Кайсын да булса югалтсак, физик яктан да, рухи яктан да көчсезләнәбез. «12 адым» сәгать ярым эчендә бәйлелекнең нәрсә икәнен һәм ул тудырган хис-тойгыларның ничек һәм ни өчен барлыкка килгәнен аңлата.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 214

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+